Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLVI-2**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 22 октябре

2017 елның 24 июлендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының XX-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерацисе Җир кодексының 72 маддәсе, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" №131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм үзидарәлек контролен гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында" 294-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елның 24 июлендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының XX-7 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендәге җирләрне файдалануга муниципаль җир контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.10 бүлегенең 88 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 3 пунктча белән тулыландырырга:

"Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча җир кишәрлеген рөхсәт ителгән файдалану һәм (яки) җир кишәрлекләрен файдалануның билгеләнгән чикләүләр нигезендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру рөхсәт ителмәгән җир кишәрлегендә урнаштыру факты ачылган очракта үзидарәлек инспекторы тикшерү төгәлләнгән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча әлеге җир кишәрлеге урнашкан җирлекнең җирле үзидарә органына яки әлеге җир кишәрлегенең авыллар (хуҗалыклар) арасындагы территориядә урнашу очрагында муниципаль районның җирле үзидарә органына рөхсәтсез төзелеш алып барылу ачыклануы турында күрсәтелгән фактны раслаучы документларны теркәп хәбәрнамә юллый".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М. ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов